РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ
РАЙОН СОВЕТ
КАЙБИЦКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАЙБЫЧ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ

КАРАР

«20» май 2022 ел

№ 1-49

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кайбыч авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Кайбыч авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, "Коррупциягә каршы тору турында" 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, "Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен тикшереп тору турында" 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законнар, Россия Федерациясе Президентының 2013 елның 8 июлендәге 613 номерлы Указы, Россия Федерациясе Президентының 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы "Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү һәм керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмә формасын раслау турында" Указы, Татарстан Республикасы Президентының 2010 елның 11 гыйнварындагы ПУ-4 номерлы "Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүгә дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәтләре һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирү турында" Указы нигезендә Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кайбыч авыл җирлеге Советы

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кайбыч авыл җирлеге Советының 2016 елның 21 апрелендәге 11-1 номерлы “Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кайбыч авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Кайбыч авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында” карары белән расланган Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кайбыч авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүгә дәгъва итүче гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр, шулай ук Кайбыч авыл җирлегендә муниципаль вазыйфалар биләүче затлар тарафыннан керемнәр, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турында белешмәләр бирү турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 7 пунктның 3 пунктчасын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) әгәр мондый алыш-бирешләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) хисап чорына кадәрге өч ел эчендә гомуми кеременнән артып китсә, хисап чорында (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (туплау) капиталларында катнашу өлеше, пайлары) сатып алу буенча һәр алыш-биреш буенча шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары һәм бу алыш-бирешләр башкарган акчаларны алу чыганаклары турында белешмәләр.».

2. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм районның рәсми сайтында http://buinsk.tatarstan.ru. һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адрес буенча урнаштырылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

ТР Буа муниципаль районы Кайбыч
авыл җирлеге башлыгы С.И. Нуретдинова